| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 24 декабрь г.Казань № 1214

Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) белән каралган, шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда, Гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторлары) кертелмәгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең төбәк исемлеген (классификаторын) раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $69^2$ статьясындагы 3 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының норматив хокук актларында (муниципаль хокук актларында), шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне башкарганда күрсәтелүе һәм башкарылуы күздә тотылган, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторларына) кертелмәгән дәүләт хезмәтләренең (муниципаль хезмәтләрнең) һәм эшләрнең региональ исемлеген (классификаторын) формалаштыру, алып бару һәм раслау тәртибен раслау турында» 2018 ел, 18 июль, 578 нче карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Კ Карарга теркәлгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актлары (муниципаль хокукый актлар) белән каралган, шул исәптән Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча вәкаләтләрне гамәлгә

ашырганда, Гомумроссия база (тармак) исемлекләренә (классификаторлары) кертелмәгән дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең һәм эшләрнең төбәк исемлеген (классификаторын) расларга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин